ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 62-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 62-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 28 марты
№ 241-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.А. Чубаров
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2014 елның 24 июлендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гражданның язма рәвештә бәян ителгән мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать җибәрелә торган органның исеме йә тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, йә тиешле затның вазыйфасы, шулай ук тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын бәян итү, гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), җавап, мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турындагы хәбәр җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелергә, шәхси имзасы һәм дата куелырга тиеш.»;

б) 3 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Язма мөрәҗәгатьтә аны җибәргән гражданның фамилиясе яисә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми.»;

в) 5 өлештә икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта), шулай ук җавап, мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турындагы хәбәр җибәрелергә тиешле электрон почта адресын йә «Дәүләт хезмәтләре (функцияләре) һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Бердәм портал) кулланганда шәхси кабинет адресын (уникаль идентификаторын) яисә гражданның идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен тәэмин итә торган дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының башка мәгълүмат системасын (алга таба – башка мәгълүмат системасы) мәҗбүри рәвештә күрсәтергә тиеш.»;

г) 6 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

2) 11 статьяның 5 өлешендәге 1 пунктында «атасының исеме» сүзләреннән соң «(соңгысы – булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

3) 16 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) шикаятьне карау нәтиҗәләре һәм аның буенча кабул ителгән карар турында законнарда билгеләнгән срокта гражданга, аның белән килештереп, шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы йә граждан Бердәм порталда яисә башка мәгълүмат системасында шәхси кабинетын кулланганда гражданның Бердәм порталда яисә башка мәгълүмат системасында шәхси кабинеты адресы (уникаль идентификаторы) буенча электрон документ рәвешендә яисә телдән хәбәр итәргә;»

4) 20 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Күмәк мөрәҗәгатьтә җавап җибәрелергә тиешле зат билгеләнмәгән булса, җавап мөрәҗәгать итүче гражданнар (имза салучылар) исемлегендә алар тарафыннан күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә, алар тарафыннан күрсәтелгән электрон почта адресы йә граждан Бердәм порталда яисә башка мәгълүмат системасында шәхси кабинетын кулланганда гражданның Бердәм порталда яисә башка мәгълүмат системасында шәхси кабинеты адресы (уникаль идентификаторы) буенча электрон документ рәвешендә җибәрелә.»;

б) 3 өлештә «Бердәм порталда шәхси кабинетлар адреслары буенча» сүзләрен «Бердәм порталда яисә башка мәгълүмат системасында шәхси кабинетлар адреслары (уникаль идентификаторлары) буенча» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләрен федераль законнарга кертелгән үзгәрешләр белән килештерү максатларында эшләнде.

Әлеге үзгәрешләр Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына электрон документ рәвешендә мөрәҗәгать итү хокукын гамәлгә ашыруга бәйле хокук мөнәсәбәтләрен камилләштерү кирәклегеннән чыгып кабул ителде.

2025 елның 30 мартыннан үз көченә керә торган 547-ФЗ номерлы Федераль закон белән мөрәҗәгать дигәндә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка, гражданнарның идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен тәэмин итә торган дәүләт хезмәтенең Бердәм порталы, шулай ук дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының башка мәгълүмат системасы йә аларның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтын кулланып, язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә юлланган тәкъдим, гариза яисә шикаять аңлашыла.

Күрсәтелгән үзгәрешләр «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән җайга салына торган нигезләмәләргә кагыла, шуңа бәйле рәвештә әлеге Законның 4, 11, 16 һәм 20 статьяларына тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

Закон проекты ике статьядан тора. 1 статья «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына кертелә торган үзгәрешләрне күздә тота. 2 статья законның рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керү тәртибен күздә тота.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылырга, үзгәртергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.